БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 09 2024 ел № 239

Спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Балтач районы прокуратурасының 2024 елның 04 мартындагы 02-08-01-2024/Прдп47-24-20920011 номерлы протесты нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 06 августындагы 226 номерлы карары белән расланган спорт разрядын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Спорт разрядын бирү өчен түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

1) шәхесне таныклаучы документ (КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә бирелә);

2) күрсәтмә яисә мөрәҗәгать:

- документ формасында кәгазьдә;

- Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланып, электрон рәвештә.

Тәкъдим яисә мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар куела:

а) төп судья коллегиясе рәисе (баш судья) кул куйган барлык спорт разрядларын бирү өчен нормаларны, таләпләрне һәм аларны үтәү шартларын үтәүне чагылдыра торган ярышларның беркетмәсе яисә беркетмәдән өземтә;

б) судьялар коллегиясе рәисе (баш судья) кул куйган судьялар коллегиясенең составы һәм квалификациясе турында белешмәнең күчермәсе (халыкара ярышлардан тыш);

в) тиешле спорт төре буенча спорт судьясының халыкара категориясе булуын раслаучы документларның күчермәләре һәм рус теленә таныкланган тәрҗемәсе һәм тиешле халыкара спорт федерациясенең календарь планына кертелмәгән халыкара ярышлар өчен «Бөтенроссия категорияле спорт судьясы» таныклыкларының күчермәләре – КМС спорт разряды бирү өчен. Күрсәтелгән документларның күчермәләре спортчы нормаларны, таләпләрне һәм шартларны үтәгән ярышларда хөкемдарлык итүне гамәлгә ашыручы

судьялар коллегиясе составына кертелгән спорт судьяларына тапшырыла: тиешле халыкара спорт федерациясенең календарь планына кертелмәгән халыкара ярышлар өчен - 5, калган ярышлар өчен - 3.

Документларны электрон рәвештә тапшырганда нотариусның электрон имзасы белән имзаланган нотариаль таныкланган тәрҗемә бирелә.

г) 3 x 4 см зурлыгындагы ике фоторәсем («Беренче спорт разряды, КМС спорт разрядлары бирү өчен»);

д) спортчының физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмага каравын раслый торган документның күчермәсе (исемлеккә кертелгән физкультура-спорт оешмасы тарафыннан спорт разряды бирү өчен документлар тапшырылган очракта региональ спорт Федерациясенең Дәүләт аккредитациясе гамәлдә булу туктатылган очракта);

е) Россия Федерациясе гражданы паспортының икенче һәм өченче битләренең күчермәләре, шулай ук яшәү урыны турында белешмәләр булган битләрнең күчермәләре, ә ул булмаганда-Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы Россия Федерациясе гражданы паспортының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), документны биргән орган, документның гамәлдә булу срогы тәмамлану датасы турында белешмәләр булган битләренең күчермәләре (яшүсмерләр спорт разрядларыннан тыш);

Документлар электрон рәвештә тапшырылганда шәхесне таныклаучы документтан белешмәләр интерактив порталь формада тиешле кырларга кертелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып запрос җибәрү юлы белән тикшерелә.

14 яшькә җитмәгән затлар өчен - туу турында таныклыкның күчермәсе.

Документлар электрон рәвештә тапшырылганда туу турында таныклыктан белешмәләр тиешле кырларга интерактив порталь формада кертелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып запрос җибәрү юлы белән тикшерелә. Туу турында таныклык чит телдә бирелгән очракта, төп нөсхәне һәм аның нотариаль таныкланган тәрҗемәсен тәкъдим итәргә кирәк. Документлар электрон формада бирелгәндә нотариусның электрон имзасы куелган нотариаль таныкланган тәрҗемә бирелә.

Чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр тарафыннан Россия Федерациясе гражданы паспортының күрсәтелгән күчермәләре урынына хәрби билет күчермәсе тапшырылырга мөмкин;

ж) спортчының спорт разряды бирү өчен нормаларны, таләпләрне һәм аларны үтәү шартларын үтәгән физкультура чарасы һәм (яисә) спорт ярышлары турындагы нигезләмәнең (регламентның) күчермәсе;

з) тиешле ярышта катнашкан Россия Федерациясе субъектларының яисә Россия Федерациясе субъектларының календарь планына кертелмәгән (халыкара ярышлар өчен) һәм Россия Федерациясе субъектларының (бөтенроссия һәм регионара ярышлар өчен) саны турында белешмәләр булган төп судья тарафыннан имзаланган документның (белешмәнең, беркетмәнең) күчермәсе.»;

1.2. 2.8.2 пунктта:

- «а» пунктчасында «Бердәм бөтенроссия спорт классификациясенә кертелгән» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлекле «д» һәм «е» пунктчалары өстәргә:

«д) спорт разряды бирү документларында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне ачыклау;

е) спорт разряды бирү өчен документлар һәм тәкъдимнәр тапшыру срокларын бозу.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» Интернет-ресурсында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов